**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Югары Стәрле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Югары Стәрле авылы №60-37 «25» август 2017 ел.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бүлеп бирелгән урыннар һәм биналар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 5.3 өлеше нигезендә

Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге (алга таба - Югары Стәрле авыл җирлеге) территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бирелгән урыннар исемлеген билгеләргә (1 нче кушымта).
2. Югары Стәрле авыл җирлегендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен урыннар исемлеген билгеләргә (2 нче кушымта).
3. Югары Стәрле авыл җирлегендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен урыннар бирү тәртибен расларга (3 нче кушымта).
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә

Рәис Л.С.Сабирҗанова